**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Югары Стәрле авылы №116-73 от « 13 » ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге № 115 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына өстәмәләр кертү турында (14.08.2015 №142, 29.10.2015 №13-6, 24.04.2018 №94-58 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 статьясындагы 2 пункты һәм 406 статьясындагы 1 пункты нигезендә

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге № 115 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (14.08.2015 №142, 29.10.2015 №13-6, 24.04.2018 №94-58 карарлар редакциясендә) түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1 2 пунктта:

а) 2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«фатир өлешләре»;

б) 3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

"торак йортлар өлешләре".

2. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында- "Маяк" газетасында басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм физик затлар мөлкәтенә салымны исәплә үгә бәйле рәвештә 2017 елның 1 гыйнварыннан башлап хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tastan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.С.Сабирҗанова